ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ
КОМИТЕТ АГРЫЗСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул. Гагарина, д.13, г. Агрыз, 422230

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘГЕРҖЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Гагарин ур.,13, Әгерҗе шәһәре, 422230

Тел.: (85551) 2-22-46; Факс: 2-22-46; E-mail: isp.agryz@tatar.ru; www. agryz.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«30» апреля 2020 ел № 141

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль
районы буенча 2020 елга торак мәйданының
1 квадрат метрының уртача базар бәясен раслау турында

"Бәяләр диапазонын билгеләү турында" 2020 елның 16 мартындагы 50 номерлы "Татарстан Республикасы бәяләүчеләр берлеге" коммерцияле булмаган партнерлыгының хаты, Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының «2020 елда Татарстан Республикасында торак базарын тикшерү турында мөрәҗәгатьне карау хакында» 2019 елның 27 августындагы 01-09-11719 номерлы хаты, «Бәя бирү эшчәнлегенә бәйле социаль әһәмиятле мәсьәләләрне хәл иткәндә эксперт һәм консультация ярдәмен гамәлгә ашыруга чыгымнарны финанс белән тәэмин итү максатларында коммерциягә карамаган оешмаларга (дәүләт (муниципаль) учреждениеләргә субсидияләр бирүдән тыш) Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 елның 13 мартындагы 182 номерлы карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының "”Татарстан Республикасы халкын сыйфатлы торак һәм торак-коммуналь хуҗалык хезмәт күрсәтүләре белән тәэмин итү" дәүләт программасын раслау турында" 03.10.2019 № 888 карары, «Соңиаль файдаланудагы торак фондының торак урыннары наем шартнамәләре буенча гражданнарның аларга торак урыннары бирү хокукларын гамәлгә ашыру турында» 2015 елның 16 мартындагы 13-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы, «Татарстан Республикасы муниципаль районнарының һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарына 2016 елгы Бөтенроссия авыл хуҗалыгы исәбен алуга әзерлек һәм аны үткәрү вәкаләтләрен бирү турында» 2014 елның 14 маендагы 31-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. 2020 елга Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы буенча торак урынның гомуми мәйданының 1 квадрат метрының бәясе нормативын билгеләргә:

1.1. Әгерҗе шәһәрендә яшь гаиләләргә торак сатып алу өчен соңиаль түләү күләмен исәпләү өчен - 33 065 сум, Әгерҗе муниципаль районында 24 272 сум;
сум, Әгерҗе муниципаль районында-38 462 сум.

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Әгерже муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга (http://www.agryz.tatarstan.ru).

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Әгерже муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары И. И. Шәмсетдиновка йөкләргә.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **А.С. Авдеев**